<table>
<tr>
<td>

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

ЧЕРЕМШАНСКИЙ

МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная, дом 8, с.Карамышево, 423119

</td>
<td>

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 8 нче йорт, Кармыш авылы, 423119

</td>
</tr>
<tr>
<td colspan="2">тел./факс email: 8-(84396) 4-22-23.Karam.Cmn.2@tatar.ru</td>
</tr>
</table>


30.04.2021ел №14

**Постановление** **Карар**

**2020 елның 31 мартында кабул ителгән «2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2020 елның 31 мартындагы 5 номерлы карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2020,2021 һәм аннан соңгы елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»;
2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең 2020, 2021 һәм аннан соңгы елларга салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен расларга».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Кармыш авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.И.Фәтхетдинов**